**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6345**
**05.12.2019**

Башкарма комитетның
аерым карарлары үз көчен
югалтуны тану турында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне приватизацияләү турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 32.1 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 3.18, 5.21, 5.23 пунктлары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның аерым карарлары үз көчен югалтуны танырга:

1) 2010 елның 22 сентябрендә «Челнинские известия» газетасының 182-183 номерларында басылып чыккан «Җәмәгать тәкъдимнәре аша муниципаль милекне сатуда катнашуга гариза формаларын раслау турында» 2010 елның 20 сентябрендәге 6036 номерлы;

2) 2014 елның 19 ноябрендә «Челнинские известия» газетасының 86 номерында басылып чыккан «Башкарма комитетның «Җәмәгать тәкъдимнәре аша муниципаль милекне сатуда катнашуга гариза формаларын раслау турында» 2010 елның 20 сентябрендәге 6036 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 17 сентябрендәге 5622 номерлы;

3) 2015 елның 26 июнендә «Челнинские известия» газетасының 46 номерында басылып чыккан «Башкарма комитетның «Җәмәгать тәкъдимнәре аша муниципаль милекне сатуда катнашуга гариза формаларын раслау турында» 2010 елның 20 сентябрендәге 6036 номерлы карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 16 июнендәге 3636 номерлы;

4) 2011 елның 23 мартында «Челнинские известия» газетасының 47 номерында басылып чыккан «Муниципаль милекне бәясен игълан итмичә сату турында нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 17 мартындагы 1246 номерлы;

5) «Башкарма комитетның «Муниципаль милекне бәясен игълан итмичә сату турында нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 17 мартындагы 1246 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 16 июнендәге 3638 номерлы.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны, шулай ук «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин